**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об Инспекции по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан

В целях совершенствования деятельности по осуществлению полномочий Российской Федерации в сфере образования и полномочия Российской Федерации по подтверждению документов об ученых степенях, ученых званиях, переданных для осуществления органам государственной власти Республики Татарстан, в соответствии со статьей 94 Конституции Республики Татарстан и Законом Республики Татарстан от 6 апреля 2005 года № 64-ЗРТ «Об исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан» **постановляю:**

1. Согласиться с предложением Кабинета Министров Республики Татарстан о создании Инспекции по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан и передаче ей функций Департамента надзора и контроля в сфере образования Министерства образования и науки Республики Татарстан.

2. Установить, что Инспекция по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан является исполнительным органом государственной власти Республики Татарстан, осуществляющим:

полномочия Российской Федерации в сфере образования, переданные для осуществления органам государственной власти субъектов Российской Федерации в соответствии со статьей 7 Федерального закона от 29 декабря 2012 года № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»;

полномочие Российской Федерации по подтверждению документов об ученых степенях, ученых званиях, переданное для осуществления органам государственной власти субъектов Российской Федерации в соответствии со статьей $6^3$ Федерального закона от 23 августа 1996 года № 127-ФЗ «О науке и государственной научно-технической политике».

3. Утвердить структуру Инспекции по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан (прилагается).

4. Внести изменение в структуру исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, утвержденную Указом

Президента Республики Татарстан от 25 сентября 2015 года № УП-899 «О структуре исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 31 мая 2016 года № УП-491), дополнив раздел IV «Иные республиканские органы исполнительной власти (ведомства Республики Татарстан)» абзацем следующего содержания:

«Инспекция по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан».

5. Кабинету Министров Республики Татарстан:

обеспечить осуществление в соответствии с законодательством комплекса мероприятий по исполнению пункта 1 настоящего Указа;

разработать и утвердить положение об Инспекции по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан, установить предельную численность ее работников, решить иные организационные, материально-технические и финансовые вопросы деятельности Инспекции по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан;

внести изменения в Положение о Министерстве образования и науки Республики Татарстан, предельную численность его работников, а также утвердить структуру Министерства образования и науки Республики Татарстан;

обеспечить своевременное представление в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по контролю и надзору в сфере образования, в части переданных полномочий Российской Федерации, указанных в абзаце втором пункта 2 настоящего Указа:

ежеквартального отчета о расходовании предоставленных субвенций, о достижении целевых прогнозных показателей;

необходимого количества экземпляров нормативных правовых актов, принимаемых органами государственной власти Республики Татарстан, по вопросам переданных полномочий;

информации (в том числе баз данных), необходимой для формирования и ведения федеральных баз данных по вопросам контроля и надзора в сфере образования;

обеспечить своевременное представление в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по контролю и надзору в сфере образования и науки, в части переданного полномочия Российской Федерации, указанного в абзаце третьем пункта 2 настоящего Указа:

ежеквартального отчета о достижении целевых прогнозных показателей;

необходимого количества экземпляров нормативных правовых актов, принимаемых органами государственной власти Республики Татарстан, по вопросам подтверждения документов об ученых степенях, ученых званиях;

информации (в том числе баз данных), необходимой для формирования и ведения федеральных баз данных по вопросам контроля и надзора в сфере образования и науки;

внести предложения об установлении количества должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан в Министерстве образования и науки Республики Татарстан и Инспекции по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан с учетом настоящего Указа;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию;

внести предложения по приведению актов Президента Республики Татарстан в соответствие с настоящим Указом.


6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
02 августа 2017 года
№ УП-662

Утверждена
Указом Президента
Республики Татарстан
от «02» августа 2017 года
№ УП-662

**Структура**
**Инспекции по контролю и надзору в сфере образования Республики Татарстан**



**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе турында**

Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен тапшырылган мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең гыйльми дәрәҗәләр, гыйльми исемнәр турындагы документларны раслау буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясен оештыру һәм аңа Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты функцияләрен тапшыру турындагы тәкъдиме белән килешергә.

2. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең түбәндәгеләрне башкаручы башкарма органы булып тора дип билгеләргә:

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына башкару өчен тапшырылган мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе вәкаләтләрен;

«Фән һәм фән-техника өлкәсендә дәүләт сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законның $6^3$ статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына башкару өчен тапшырылган гыйльми дәрәҗәләр, гыйльми исемнәр турындагы документларны раслау буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен.

3. Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясенең структурасын расларга (кушымта итеп бирелә).

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-899 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына, «Республиканың башка башкарма хакимият органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары)» дигән IV кисәккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

законнар нигезендә әлеге Указның 1 пунктын үтәү йөзеннән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе турында нигезләмәне эшләргә һәм расларга, хезмәткәрләренең чик санын билгеләргә, Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе эшчәнлегенә кагылышлы башка оештыру, матди-техник һәм финанс мәсьәләләрен хәл итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турында нигезләмәгә, хезмәткәрләренең чик санына үзгәрешләр кертергә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының структурасын расларга;

әлеге Указның 2 пункты икенче абзацында күрсәтелгән Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтләрне үтәгәндә мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен тормышка ашыручы федераль башкарма хакимияте органына түбәндәгеләрне үз вакытында тапшыруны тәэмин итәргә:

һәр квартал саен бүлеп бирелгән субвенцияләрне тоту, максатчан фаразлау күрсәткечләренә ирешү турында хисапны;

тапшырылган вәкаләтләр мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларның тиешле сандагы нөсхәләрен;

мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек мәсьәләләре буенча федераль база формалаштыру һәм аны тулыландыру өчен кирәкле булган мәгълүматны (шул исәптән мәгълүматлар базасын);

әлеге Указның 2 пункты өченче абзацында күрсәтелгән Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтләрне үтәгәндә мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен тормышка ашыручы федераль башкарма хакимияте органына түбәндәгеләрне үз вакытында тапшыруны тәэмин итәргә:

һәр квартал саен максатчан фаразлау күрсәткечләренә ирешү турында хисапны;

гыйльми дәрәҗәләр, гыйльми исемнәр турындагы документларны раслау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларның тиешле сандагы нөсхәләрен;

мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек мәсьәләләре буенча федераль база формалаштыру һәм аны тулыландыру өчен кирәкле булган мәгълүматны (шул исәптән мәгълүматлар базасын);

әлеге Указны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында һәм Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары санын билгеләү турында тәкъдим кертергә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруга бәйле башка карарлар кабул итәргә;

Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү турында тәкъдимнәр кертергә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 02 август
№ ПУ-662

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның « 02 » августындагы
ПУ- 662 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасының мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек инспекциясе структурасы**

